# Технологиядән тозлы камырдан композиция ясау буенча мастер-класс

*Апас районы Тәүгелде*
*башлангыч мәктәбе укытучысы*
*Музафарова Гөлназ*
*Гыйлметдин кызы*

# Максат:

**Композиция төшенчәсе белән таныштыру. Тозлы камыр белән бизәкләр төшерергә өйрәнү.Укучыларны матурлыкны күрә белергә өйрәтү.**

# *Кирәкле материаллар*

Бер өлеш тоз, бер өлеш он, ½ су һәм бер бал кашыгы сыек май.

Гуашь, пумала, төссез лак, ДВП



# Эш барышы

*Тозны җылы суда эретәбез һәм шуңа он, сыек май кушып тыгыз массалы камыр ясыйбыз (тозның бик вагын алабыз)*




*Бу композициягә камырны төсле ясыйбыз. Иң беренче камырны ике өлешкә бүләбез. Җимешләрен кызыл, ә яфракларын яшел төскә манабыз.*

*Камырны 30-60 минутка суыткычка тыгабыз.*



***Композицияне урнаштыру өчен өслек ясыйбыз. ДВПга обойны урнаштырабыз. Шушы өслеккә беренче эш итеп каен ботагын “Момент” кләе белән ябыштырабыз.***



***Кызыл төстәге камырдан түгәрәк шарчыклар ясыйбыз. Болар-миләш тәлгәшләре була.***



***Шарчыкларның аскы өлешенә пумала ярдәмендә батынкы тишек ясыйбыз. Яшел төстәге камырдан яфраклар урнаштырабыз, пычак ярдәмендә яфракларның буыннарын билгелибез. Барысын да ПВА кләе белән ябыштырабыз.***



## Әзер композициябезне кояшка яки батареяга  1-2 көнгә куябыз.





***Копозициябезне ахырдан төссез лак белән буйыйбыз.***



# Эшегездә уңышлар телибез!

